# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы
«Лебедино авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең
Новоспасск авыл торак пунктында 2023 елда гражданнарның үзара
салымын кертү турында

**13.10.2022ел** **№2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел, №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы «Лебедино авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Новоспасск авыл торак пункты гражданнары җыены

**КАРАР БИРДЕ:**

1. 2023 елда Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Лебедино авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Новоспасск авыл торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертергә, 1 группа инвалидларыннан, көндезге бүлектә укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына чакырылган гражданнардан тыш.

2.Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә, түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтергә:

- юлларга таш түшәү;
- техниканы карап тоту-тракторны;
- мәдәни мирас һәйкәлен карап тоту.

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта Лебедино авыл җирлеге башкарма комитетына акчаларны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә рөхсәт бирергә.»

3. Әлеге карарны Лебедино авыл җирлегенең Новоспасск авылы мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән, Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында (http:// alekseevskiy.tatarstan.ru.), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (httr://pravo.tatarstan.ru) бастырып кабул халыкка җиткерергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Алексеевск муниципаль районы
Лебедино авыл җирлеге башлыгы ____________ Токарев Ю.И.
(имза) (имзаның расшифровкасы)